**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

« 05 » декабрь 2025 ел № 3/6

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендәге 39/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, район уставы, 2025 елның 22 сентябрендәге 02-08-03-2025/559-25-20920036 номерлы прокуратура протесты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендәге 39/1номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13.8 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 15.9 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазифаи затлары» сүзләренә алыштырырга;

1.3. 15.10 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

1.4. 15.11 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасының иң югары вазифаи затлары» сүзләренә алыштырырга;

1.5. 15.13 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

1.6. 15.14 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

1.7. 17 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 17.2.1 пунктын өстәргә:

«17.2.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль хезмәт вазифасын биләү турында үтенеч белән гариза;

2) әлеге Нигезләмәнең 16.1. каралган анкета;

3) паспорт;

4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

5) белем һәм квалификация турында документ;

6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан

тыш;

7) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары – запаста булган гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулый торган авыруның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

10) муниципаль хезмәткә кергән елга кадәрге ел өчен керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;

10.1) әлеге Нигезләмәнең 16 статьясында каралган белешмәләр;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.».

1.8. 17.2.1 пунктының 5 пунктчасында «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлекләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе Г.Г.Минакова